РОГОЗ ШИРОКОЛИСТНЫЙ — киң яфраклы җикәнбаш
РОГОЛИСТНИК КРЫЛАТЫЙ — канатлы мөгезьяфрак
РОГОЛИСТНИК ТЁМНО-ЗЕЛЁНЫЙ — куе яшел су кычытканы, куе яшел мөгезьяфрак
РОГУЛЬНИК *(водяной орех)* — батманчык, су чикләвеге
РОЖЬ ДИКАЯ — кыргый арыш
РОЖЬ ОЗИМАЯ — көзге арыш, уҗым арышы
РОЖЬ ПОСЕВНАЯ — чәчү арышы, игү арышы
РОЗА — гөлчәчәк, роза
РОЗА ЗОЛОТАЯ — алтын камчы
РОЗА КОРИЧНАЯ — гөлҗимеш, гөләп
РОЗА СОБАЧЬЯ — эт борыны, әрсез гөлҗимеш
РОЗАРИЙ — роза бакчасы
РОЗЕТКА ЛИСТЬЕВ — яфрак таралгысы
РОЗМАРИН — бәбрия (куак)
РОМАШКА — ак чәчәк, ромашка
РОМАШКА АПТЕЧНАЯ — дару ромашкасы
РОМАШКА ЛУГОВАЯ — болын ромашкасы
РОМАШКА ОБЫКНОВЕННАЯ — сарыбаш
РОМАШКА ПАХУЧАЯ — исле ромашка, исле үлән
РОМАШКА НЕПАХУЧАЯ — болан күзе
РОСИЧКА — кыргый тары
РОСТ — үсү
РОСТ АПИКАЛЬНЫЙ — очтан үсү
РОСТ ИНТЕРКАЛЯРНЫЙ — буын араларыннан үсү
РОСТОК — шытым
РОСЯНКА — чыклы үлән, чык үләне
РОСЯНКА КРУГЛОЛИСТНАЯ — түгәрәк яфраклы чыклы үлән
РУДЕРАЛЬНЫЕ РАСТЕНИЯ — чүп үләннәр
РЫЖИК МЕЛКОПЛОДНЫЙ — вак орлыклы шепкән
РЫЖИК ПОСЕВНОЙ — чәчүлек шепкән, чыпчык орлыгы
РЫЛЬЦЕ — җимешлек авызчыгы
РЭГНЕРИЯ СОБАЧЬЯ — эт саруты
РЯБИНА ОБЫКНОВЕННАЯ — миләш
РЯБИНА ЧЕРНОПЛОДНАЯ *(арония)* — кара миләш
РЯБИННИК РЯБИНОЛИСТНЫЙ — миләш яфраклы куак
РЯБЧИК МАЛЫЙ — кечкенә шадра үлән
РЯСКА МАЛАЯ — вак бака тәңкәсе
РЯСКА ТРЁХДОЛЬНАЯ — өч аерчалы бака тәңкәсе



## С

САБЕЛЬНИК БОЛОТНЫЙ — саз бишьяфрагы, саз утчәчәге
САЛЬВИНИЯ ПЛАВАЮЩАЯ — йөзгәләк тәңкә яфрак
САЖЕНЕЦ — үсенте, утыртма агач
САКСАУЛ — саксаул (чүл куагы)
САКУРА — сакура (декоратив чия куагы)
САЛАТ — салат (яшелчә үсемлек)
САЛАТ ОГОРОДНЫЙ *(латук посевной)* — игүле салат
САМООПЫЛЕНИЕ — үзеннән серкәләнү
САМШИТ — самшит (мәңге яшел үсемлек)
САНДАЛОВОЕ ДЕРЕВО — бәкам агачы
САРГАССУМ — саргассум (суүсемнәрнең бер ыругы)
САХАРНЫЙ ТРОСТНИК — шикәр камышы
СВЁКЛА — чөгендер
СВЁКЛА КОРМОВАЯ — азык чөгендере, терлек чөгендере
СВЁКЛА МНОГОЛЕТНЯЯ — күпьеллык чөгендер
СВЁКЛА САХАРНАЯ — шикәр чөгендере
СВЁКЛА СТОЛОВАЯ — аш чөгендере
СВЕРБИГА ВОСТОЧНАЯ — кончыгыш какысы, әче какы
СВЕРГУБЕЦ — ачы какы
СВЕЧЕНИЕ РАСТЕНИЙ — үсемлекләрнең нурланышы
СЕЛЕЗЕНОЧНИК ОЧЕРЕДНОЛИСТНЫЙ — алмаш яфраклы талак үләне
СЕЛЕКЦИЯ — сайлап алу
СЕЛЬДЕРЕЙ — сельдерей (аш тәмләткеч үсемлек)
СЕМЕННИК — орлыклык
СЕМЕНА — орлыклар
СЕМЯДОЛИ — орлык өлешләре
СЕМЯНОЖКА — орлык сабы
СЕМЯПОЧКА — орлык бөресе
СЕРАДЕЛЛА — кош тәпие, сераделла (азык үлән)
СЕРДЕЧНИК ГОРЬКИЙ — ачы кардамин
СЕРДЕЧНИК ЛУГОВОЙ — болын кардамины
СЕРДЕЧНИК МНОГОЦВЕТКОВЫЙ — вак чәчәкле кардамин, вак чәчәкле кына
СЕРДЕЧНИК НЕДОТРОГА — тидермәс кардамин
СЕРДЦЕВИНА — үзәк, агач үзәге
СЕРЁЖКА — сырга, алка чәчәк
СЕРПУХА — сары буяк (бүлмә гөле)
СЕЯНЕЦ — чәчкен

СИНЕГОЛОВНИК — чәнчү уты, чәнчәвек
СИНЕГОЛОВНИК ПЛОСКОЛИСТНЫЙ — җәенке яфраклы чәнчү уты
СИНЮХА ГОЛУБАЯ — йонча гөл, күкчел
СИНЯК ОБЫКНОВЕННЫЙ — гади елан үләне, әңгерәк уты
СИРЕНЬ ВЕНГЕРСКАЯ — венгр сирене
СИРЕНЬ ОБЫКНОВЕННАЯ — сирень, канәфер куагы (чәчәге)
СИТНИК ЛЯГУШАЧИЙ — бака ялтырагы, бака кугасы
СИТНИК НИТЕВИДНЫЙ — җепсыман ялтырак, җепсыман куга
СИТНИК СПЛЮСНУТЫЙ — ямьшек куга
СИТНЯГ БОЛОТНЫЙ — сазлавык уты
СИТНЯГ ИГОЛЬЧАТЫЙ — энәле сазлавык уты
СИТНЯГ ОДНОЧЕШУЙЧАТЫЙ — бер кабырчыклы сазлавык уты
СИТНЯГ ПРОМЕЖУТОЧНЫЙ — арадаш сазлавык уты
СКАБИОЗА — камчау, кычу үләне
СКАБИОЗА ЖЁЛТАЯ — сары ялмача, сары камчау
СКЕРДА КРОВЕЛЬНАЯ — япмалы сарыбаш, елкы уты
СКЕРДА СИБИРСКАЯ — себер какычасы, себер сарыбашы
СКЛЕРЕИДЫ — склереидлар (механик тукымаларның калын стеналы күзәнәкләре)
СКЛЕРЕНХИМА — склеренхима (калын стеналы күзәнәкләрдән торган механик тукыма)
СЛИВА — слива (агачы), караҗимеш (киптерелгәне)
СМОКОВНИЦА *(инжирное дерево)* — инҗир агачы
СМОЛЁВКА ОБЫКНОВЕННАЯ *(хлопушка)* — гади шартлавык чәчәк
СМОЛЁВКА ПОНИКАЮЩАЯ — салынкы шартлавык чәчәк
СМОЛКА ОБЫКНОВЕННАЯ — гади дегет чәчәге, сагызлы чәчәк
СМОРОДИНА — карлыган
СМОРОДИНА БЕЛАЯ — ак карлыган
СМОРОДИНА КРАСНАЯ — кызыл карлыган
СМОРОДИНА ПУШИСТАЯ — йөнтәс карлыган
СМОРОДИНА ЧЁРНАЯ — кара карлыган
СНЕЖНОЯГОДНИК БЕЛЫЙ — кар җиләге
СНЫТЬ ОБЫКНОВЕННАЯ — гади сәрдә
СОЗРЕВАНИЕ — өлгерү
СОЛНЦЕЦВЕТ — кояш чәчәк, көнчәчәк
СОЛОДКА ГОЛАЯ — яфраксыз татлы тамыр
СОЛЯНКА ХОЛМОВАЯ — тозлак (үсемлек)
СОН РАСТЕНИЙ — үсемлекләр йокысы
СОПЛОДИЕ — тәлгәш, җимеш төркеме
СОРГО — сорго (азык үсемлек)



СОРУС — сорус (абага спорангийлары җыелмасы)
СОСНА ОБЫКНОВЕННАЯ — нарат (агачы)
СОСНА КЕДРОВАЯ *(кедр сибирский)* — эрбет чикләвеге, кедр нараты
СОЦВЕТИЕ — чәчәк төркеме, укмаш чәчәк
СОЦВЕТИЕ ГОЛОВКА — башча (мәс., тукранбашта)
СОЦВЕТИЕ ЗОНТИК — чатыр чәчәк төркеме (мәс., нәүрүздә)
СОЦВЕТИЕ КИСТЬ — чук чәчәк төркеме (мәс., карлыганда)
СОЦВЕТИЕ КОЛОС — башак
СОЦВЕТИЕ МЕТЁЛКА — себеркәч (солыда)
СОЧЕВИЧНИК ВЕСЕННИЙ — торна борчагы, карга кузагы, көрән чәчәк
СОЯ — соя (кузаклы үсемлек)
СПАРЖА ЛЕКАРСТВЕННАЯ — дарулы әспе үләне, чебен үләне
СПИРОГИРА — спирогира (суүсем)
СПОРА — җенессез үрчү күзәнәге
СПОРАНГИЙ — спорангий (споралар оялыгы)
СПОРОФИЛЛЫ — спорофиллар (спорангийлар үсә торган яфрак, мәс., абагаларда)
СПОРОФИТ — спорофит (үсемлекләрдә җенессез үрчү буыны)
СТАЛЬНИК ПОЛЕВОЙ — кыр каешкыраны, кыр корычтамыры
СТАЛЬНИК ПРОМЕЖУТОЧНЫЙ — арадаш каешкыран, арадаш корычтамыр
СТВОЛ — кәүсә
СТЕБЕЛЬ ВОСХОДЯЩИЙ — күтәрелмә сабак
СТЕБЕЛЬ ВЬЮЩИЙСЯ — уралма сабак
СТЕБЕЛЬ ЛАЗЯЩИЙ — үрмә сабак
СТЕБЕЛЬ ЛЕЖАЩИЙ — ятма сабак
СТЕБЕЛЬ ПОДЗЕМНЫЙ *(корневище)* — җир асты сабагы (тамырча)
СТЕБЕЛЬ ПОЛЗУЧИЙ — шуышма сабак
СТЕБЕЛЬ ПРЯМОСТОЯЧИЙ — туры сабак
СТЕБЕЛЬ СТЕЛЮЩИЙСЯ — түшәлмә сабак
СТЕБЕЛЬ ТРАВЯНИСТЫЙ — үләнчел сабак
СТЕБЕЛЬ ЦЕПЛЯЮЩИЙСЯ — сырышма сабак
СТЕБЛЕВОЙ УЗЕЛ — сабак буыны
СТОЛОН — бәрәңгенең җир асты сабагы
СТРАУСНИК ОБЫКНОВЕННЫЙ — тәвә (кошы) каурые
СТРЕЛКА — сабак, көпшә (мәс., суганда)
СТРЕЛОЛИСТ ОБЫКНОВЕННЫЙ — гади укъяфрак, су угы
СУДАНСКАЯ ТРАВА — судан үләне (азык үләне)
СУК — ботак

СУККУЛЕНТЫ — суккулентлар (бик сусыл, корылыкка чыдам үсемлекләр, мәс., алой, кактус)
СУРЕПИЦА ОБЫКНОВЕННАЯ — эт какысы, бүдәнә кузагы
СУРЕПИЦА ПРЯМАЯ — төз эт какысы, эт кузагы
СУШЕНИЦА ЛЕСНАЯ — урман кипкәре, урман үпкә үләне
СУШЕНИЦА ТОПЯНАЯ — саз кипкәре, саз киез үләне (дару үләне)
СЫТЬ *(земляной миндаль, чуфа)* — җир миндале, чуфа
СФАГНУМ — ак мүк, торф мүге

## Т

ТАБАК — тәмәке
ТАБАК ДУШИСТЫЙ — хуш исле тәмәке
ТАВОЛГА — тубылгы
ТАВОЛГА ШЕСТИЛЕПЕСТНАЯ *(земляной орех)* — алты таҗ яфракчыклы кура, җир чикләвеге
ТАЙНИК ЯЙЦЕВИДНЫЙ — күкәйсыман листер (листер уты)
ТАЛЛОМ — таллом (түбән төзелешле үсемлекләрнең гәүдәсе)
ТАЛЛОФИТЫ — таллофитлар (сабагы, яфрагы, тамыры булмаган түбән төзелешле үсемлекләр һәм гөмбәләр)
ТАЛЬНИК — таллык
ТАТАРНИК КОЛЮЧИЙ *(чертополох)* — шайтан таягы
ТЕЛИПТЕРИС БОЛОТНЫЙ — сазлык татлы абагасы
ТЕЛОРЕЗ ОБЫКНОВЕННЫЙ — гади тәнкисәр, кискеч кыяк
ТЕРЕСКЕН СЕРЫЙ — соры терескен
ТЁРН *(слива колючая)* — күгән агачы
ТЕРОФИТЫ — терофитлар (орлыктан үрчүче берьеллык үсемлекләр)
ТИМОФЕЕВКА ЛУГОВАЯ — болын арышбашы, болын сүсәне
ТИМОФЕЕВКА СТЕПНАЯ — дала арышбашы
ТИМЬЯН ОБЫКНОВЕННЫЙ *(чабрец, богородская трава)* — үрмә рәйхан, чабыр үләне
ТИПЧАК *(овсяница бороздчатая)* — сырлы солыча, сүсән солыча
ТИСС — тиле нарат (мәңге яшел ылыслы агач)
ТМИН ОБЫКНОВЕННЫЙ — ак әнис (дару үсемлеге)
ТОЛОКНЯНКА ОБЫКНОВЕННАЯ *(медвежье ушко)* — аю колагы, аю җиләге, гади аю баланы
ТОМАТ *(помидор)* — томат, помидор



ТОНОПЛАСТ — тонопласт (үсемлекләр күзәнәгендәге вакуольнең тышчасы)
ТОПОЛЬ БЕЛЫЙ *(серебристый)* — ак тупыл, ак тирәк
ТОПОЛЬ ЧЁРНЫЙ *(осокорь)* — кара тирәк, кара тупыл
ТОРИЦА ЛЬНЯНАЯ — җитен кырлыгы
ТОРИЦА ПОЛЕВАЯ — басу кырлыгы
ТОРИЦА ПОСЕВНАЯ — чәчү кырлыгы
ТОПИНАМБУР *(груша земляная)* — җир грушасы
ТОРИЧНИК КРАСНЫЙ — кызыл кырлык
ТРАХЕИ — трахеялар (үзагачтагы аркылы тышчасы җимерелеп яки тишелеп, протоплазмасы кибеп беткән вертикаль күзәнәкләр рәте)
ТРАХЕИДЫ — трахеидлар (үзагачта үткәргеч функциясен үтәүче орчыксыман күзәнәкләр)
ТРЁХРЕБЕРНИК НЕПАХУЧИЙ *(ромашка непахучая)* — иссез ромашка, иссез өчкырлык
ТОЧКА РОСТА — үсү ноктасы, үсү конусы
ТРАВА — үлән, чирәм
ТРИЛИСТНИК *(вахта трёхлистная)* — өчьяфрак
ТРИОСТРЕННИК БОЛОТНЫЙ — саз кугалыбы
ТРИЩЕТИННИК — шылдыравык солы
ТРОСТНИК САХАРНЫЙ — шикәр камышы
ТРУБКА РОСТОВАЯ — үсү көпшәсе
ТРУБКОВАНИЕ — көпшәгә утыру
ТРОСТНИК ОБЫКНОВЕННЫЙ — пумала камыш, башаклы камыш, читән камышы
ТРЯСУНКА СРЕДНЯЯ — калтыравык башак
ТРЯСУЧКА — калтыравык чәчәк
ТУНГ *(тунговое дерево)* — тунг агачы, май агачы
ТУРГОР — тургор (күзәнәк тышчасын киерелдереп торучы эчке басым)
ТУРНЕПС — терлек шалканы
ТУЯ — савыр, туя (ылыслы агач)
ТЫКВА ОБЫКНОВЕННАЯ — кабак
ТЫСЯЧЕГОЛОВ ПИРАМИДАЛЬНЫЙ — меңбаш үлән, пирамидаль меңбаш
ТЫСЯЧЕЛИСТНИК БЛАГОРОДНЫЙ — асыл меңъяфрак, ак мәтрүшкә
ТЫСЯЧЕЛИСТНИК ИВОЛИСТНЫЙ — тал яфраклы меңъяфрак
ТЫСЯЧЕЛИСТНИК ОБЫКНОВЕННЫЙ — гади меңъяфрак (дару үсемлеге)

ТЫСЯЧЕЛИСТНИК СЕВЕРНЫЙ — төньяк меңъяфрагы
ТЫЧИНКА — серкәч
ТЫЧИНОЧНАЯ НИТЬ — серкәч җебе
ТЮЛЬПАН — кызалак

## У

УЖОВНИК ОБЫКНОВЕННЫЙ — елан абагасы, елан теле
УЗЕЛ — буын, буынтык
УЗЕЛ КУЩЕНИЯ — тармаклану буыны
УКРОП ПАХУЧИЙ, ОГОРОДНЫЙ — исле укроп, туран уты
УЛОТРИКС — улотрикс (суүсем)
УЛЬВА *(морской салат)* — диңгез салаты (суүсем)
УРУТЬ — бака чыршысы, чыршы үләне, су чыршысы
УРУТЬ КОЛОСИСТАЯ — башаклы су чыршысы
УРУТЬ МУТОВЧАТАЯ — бөҗралы су чыршысы
УСТЬИЦЕ — авызчык (яфракларда)

## Ф

ФАЗА ВИЛОЧКИ — япьләнү фазасы, ике яфрак фазасы
ФАЗА КОЛОШЕНИЯ — башаклану фазасы (чоры)
ФАЗА КУЩЕНИЯ — тармаклану фазасы
ФАЗА РОСТА — үсү фазасы, үсү чоры
ФАЗА СОЗРЕВАНИЯ — өлгерү (җитлегү) чоры
ФАЗА ЦВЕТЕНИЯ — чәчәк ату чоры
ФАЗА ТРУБКОВАНИЯ — көпшәләнү чоры
ФАСОЛЬ — ногыт борчагы, фасоль
ФАСОЛЬ ОБЫКНОВЕННАЯ — гади фасоль, ногыт
ФАЦЕЛИЯ — фацелия (баллы үсемлек)
ФЕЙХОА — фейхоа (үсемлек)
ФЕЛЛЕМА — феллема (үсемлекләрнең бөке тукымасы)
ФЕЛЛОГЕН — феллоген (ул үсемлекләр сабагының тышкы ягына феллема, ә үзәгенә таба феллодерма ясый)
ФЕЛЛОДЕРМА — феллодерма (феллоген күзәнәкләреннән үсүче перидерманың эчке ягы)
ФИАЛКА ВЫСОКАЯ — биек миләүшә
ФИАЛКА ДУШИСТАЯ — хуш исле миләүшә
ФИАЛКА НОЧНАЯ *(вечерница)* — төнге миләүшә



ФИАЛКА ОПУШЕННАЯ — төкле миләүшә
ФИАЛКА ПЕСЧАНАЯ — комлык миләүшәсе
ФИАЛКА ПОЛЕВАЯ — кыр миләүшәсе, басу миләүшәсе
ФИАЛКА ПРУДОВАЯ — буа миләүшәсе
ФИАЛКА СОБАЧЬЯ — эт миләүшәсе
ФИАЛКА ТРЁХЦВЕТНАЯ *(анютины глазки)* — ала миләүшә
ФИАЛКА УДИВИТЕЛЬНАЯ — гаҗәеп миләүшә
ФИАЛКА ХОЛМОВАЯ — калкулык миләүшәсе
ФИКУС — агач гөл, фикус
ФИНИКОВАЯ ПАЛЬМА — хөрмә агачы, хөрмә пальмасы
ФИСТАШКА — цестә (агачы һәм җимеше)
ФИТОНЦИДЫ — фитонцидлар (югары төзелешле үсемлекләр бүлеп чыгара торган биологик актив матдәләр)
ФИТОПЛАНКТОН — фитопланктон (суда йөзмә хәлдә яшәүче бик вак үсемлекләр)
ФЛОКС — флокс (декоратив үсемлек)
ФЛОРА — үсемлекләр дөньясы
ФУЗАРИОЗ — фузариоз (үсемлекләрдә гөмбә авыруы)
ФУКСИЯ — тамчы гөл, алка гөл
ФУКУС — суүсем төре
ФУНДУК — бакча чикләвеге, фундук
ФИТОЦЕНОЗ — фитоценоз (үсемлекләр бергәлеге)

## Х

ХВОЙНИК *(эфедра)* — дала кура җиләге, эфедра
ХВОЙНЫЕ — ылыслы агачлар, ылыслылар
ХВОЩ — наратбаш, нарат үләне
ХВОСТНИК ОБЫКНОВЕННЫЙ — гади елан камышы, су нараты
ХВОЩ БОЛОТНЫЙ — саз наратбашы
ХВОЩ ВЕТВИСТЫЙ — тармаклы наратбаш
ХВОЩ ЗИМУЮЩИЙ — кышлаучы наратбаш
ХВОЩ ЛЕСНОЙ — урман наратбашы
ХВОЩ ЛУГОВОЙ — болын наратбашы
ХВОЩ ПОЛЕВОЙ — кыр наратбашы
ХВОЯ — ылыс
ХИННОЕ ДЕРЕВО — хина агачы
ХЛАМИДОМОНАДА — хламидомонада (суүсем)
ХЛЕБНОЕ ДЕРЕВО — икмәк агачы

ХЛОПУШКА *(смолевка обыкновенная)* — шартлавык
ХЛОПЧАТНИК *(хлопок)* — мамык (үсемлеге һәм аның сүсе)
ХЛОРЕЛЛА — хлорелла (суүсем)
ХЛОРОПЛАСТЫ — хлоропластлар, яшел пластидлар
ХЛОРОФИЛЛ — хлорофилл (хлоропласттагы яшел пигмент)
ХМЕЛЬ ВЬЮЩИЙСЯ — үрмәле колмак
ХНА — кына
ХОХЛАТКА ПЛОТНАЯ — тыгыз сәрдәнә, урман бәрәңгесе, күкебаш
ХОХЛАТКА СРЕДНЯЯ — урта сәрдәнә
ХРЕН ОБЫКНОВЕННЫЙ — керән
ХРИЗАНТЕМА — әрем гөле
ХУРМА — хөрмә (агачы һәм җимеше)

## Ц

ЦВЕТЕНИЕ — чәчәк ату
ЦВЕТОВОДСТВО — чәчәкчелек
ЦВЕТКОВЫЕ РАСТЕНИЯ — чәчәкле үсемлекләр
"ЦВЕТЕНИЕ" ВОДЫ — суның "чәчәк атуы"
ЦВЕТОК — чәчәк, гөл, чәчкә
ЦВЕТОК ЖЕНСКИЙ — ана чәчәк
ЦВЕТОК МУЖСКОЙ — ата чәчәк
ЦВЕТОК ОБОЕПОЛЫЙ — ике җенесле чәчәк
ЦВЕТОК ОДНОПОЛЫЙ — бер җенесле чәчәк
ЦВЕТОК ПЕСТИЧНЫЙ — җимшәнле чәчәк
ЦВЕТОК ТЫЧИНОЧНЫЙ — серкәчле чәчәк
ЦВЕТОЛОЖЕ — чәчәк төбе
ЦВЕТОНОЖКА — чәчәк сабы
ЦЕТРАРИЯ — цетрария (лишайник төре)
ЦИКЛАМЕН *(дряква)* — куян колагы, цикламен (миләүшә төре)
ЦИКОРИЙ ОБЫКНОВЕННЫЙ — һиндыба, буынлы чәчәк, эт каешы, фәрештә чәчәге
ЦИКУТА *(вех ядовитый)* — түндербаш, аю балтырганы
ЦИННА ШИРОКОЛИСТНАЯ — киң яфраклы цинна
ЦИРЦЕЯ ОБЫКНОВЕННАЯ — күке тамагы (вак үлән)
ЦИСТОПТЕРИС ЛОМКИЙ — мурт куык абага
ЦИТОПЛАЗМА — цитоплазма (күзәнәкнең сыек өлеше)
ЦИТРУСОВЫЕ — цитрус үсемлекләр



ЦИЦАНИЯ — су дөгесе, цицания
ЦИЦЕРБИТА — төймәчәчәк
ЦМИН ПЕСЧАНЫЙ *(бессмертник песчаный)* — шиңмәс чәчәк, комлык үлмәс чәчәге

## Ч

ЧАБЕР САДОВЫЙ — бакча рәйханы
ЧАЙ ЛУГОВОЙ — болын чәе
ЧАСТУХА — сусак, көтүче кубызы
ЧАСТУХА ПОДОРОЖНИКОВАЯ — бака яфрагысыман кәҗә кузгалагы
ЧАШЕЛИСТИКИ — кәсә яфракчыклары
ЧАШЕЧКА — кәсә (чәчәктә)
ЧЕМЕРИЦА ЛОБЕЛЯ — Лобель аксыргагы
ЧЕРЕДА — эт тигәнәге
ЧЕРЕДА ПОНИКШАЯ — саз ябышкагы
ЧЕРЕДА ТРЁХРАЗДЕЛЬНАЯ — эт тигәнәге, ябышкак сырганак
ЧЕРЁМУХА ОБЫКНОВЕННАЯ — шомырт (агачы һәм җимеше)
ЧЕРЁМУХА ВИРГИНСКАЯ — виргин шомырты
ЧЕРЕМША — кыр сарымсагы
ЧЕРЕНКИ — чыбыкчалар
ЧЕРЕШНЯ — төче чия, татлы чия
ЧЕРЕШОК — яфрак сабы
ЧЁРНАЯ НОЖКА — караяк (гөмбә авыруы)
ЧЕРНИКА — кара җиләк
ЧЕРНОБЫЛЬНИК *(полынь обыкновенная)* — кара әрем
ЧЕРНОГОЛОВКА ОБЫКНОВЕННАЯ — карабаш, божан чәчәге
ЧЕРНОГОЛОВКА КРУПНОЦВЕТНАЯ — эре чәчәкле карабаш
ЧЁРНОЕ ДЕРЕВО — карагач (тропик үсемлек)
ЧЕРНОКОРЕНЬ ЛЕКАРСТВЕННЫЙ — дарулы каратамыр, дару кырмавыгы
ЧЕРТОПОЛОХ КУРЧАВЫЙ — билчән уты
ЧЕСНОК — сарымсак
ЧЕЧЕВИЦА СЪЕДОБНАЯ — ашамлык ясмык
ЧИНА БОЛОТНАЯ — саз борчагы
ЧИНА ГОРОХОВИДНАЯ — борчаксыман чина
ЧИНА ЛЕСНАЯ — урман кырлы борчагы
ЧИНА ЛУГОВАЯ — болын кырлы борчагы, сары кәрешкә

ЧИНА ПОСЕВНАЯ — чәчүле кырлы борчак
ЧИНАР — чинар (агач)
ЧИСТЕЦ БОЛОТНЫЙ — саз нәдербашы, саз күркә борыны
ЧИСТЕЦ ВЕСЕННИЙ — күркә борыны, язгы нәдербаш, күзлут чәчәге
ЧИСТЕЦ ЛЕСНОЙ — урман нәдербашы (дару үсемлеге)
ЧИСТЕЦ ОДНОЛЕТНИЙ — берьеллык нәдербаш
ЧИСТЕЦ ПРЯМОЙ — туры күзлут
ЧИСТОТЕЛ БОЛЬШОЙ — зур канлут, төче үлән
ЧИСТЯК ВЕСЕННИЙ — язгы кырлыган, язгы фикария
ЧИХОТНАЯ ТРАВА — төчкерек уты
ЧУБУШНИК ДУШИСТЫЙ — хуш исле ясмин куагы
ЧУМИЗА — чумиза, кытай тарысы
ЧУФА *(земляной миндаль)* — чуфа, җир миндале, җир бадамы (бүлбеле майлы үсемлек)

## Ш

ШАЛФЕЙ — чебен кунмас гөл, шалфей
ШАЛФЕЙ ЛУГОВОЙ — болын шалфее
ШАЛФЕЙ МУТОВЧАТЫЙ — чуклы шалфей
ШАЛФЕЙ ОСТЕПНЁННЫЙ — далалашкан шалфей
ШАЛФЕЙ ПОНИКАЮЩИЙ — салынкы шалфей
ШАФРАН — кыр зәгъфраны (үсемлек)
ШЕЛКОВИЦА *(тутовое дерево)* — ефәк агачы, тут агачы
ШИЛЬНИК — безүлән
ШИПОВНИК — гөлҗимеш, гөләп
ШИПОВНИК ВОНЮЧИЙ — сасы гөләп
ШИПОВНИК ИГЛИСТЫЙ — энәле гөләп
ШИПОВНИК КОЛЮЧИЙ — чәнечкәк гөләп
ШИПОВНИК МЯГКИЙ — йомшак гөләп
ШИПОВНИК СОБАЧИЙ — эт гөләбе
ШИШКА — күркә (мәс., наратта)
ШЛЕМНИК КОПЬЁЛИСТНЫЙ — сөңге яфраклы калканлы ут
ШЛЕМНИК ОБЫКНОВЕННЫЙ — тургай күзлубы, гади күзлуб
ШОКОЛАДНОЕ ДЕРЕВО *(какао)* — шоколад агачы (тропик үсемлек)
ШПИНАТ ОГОРОДНЫЙ — бакча шпинаты
ШТАМБ — кәүсә, агач кәүсәсе



## Щ

ЩАВЕЛЬ — кузгалак
ЩАВЕЛЬ ВОДНЫЙ — су кузгалагы
ЩАВЕЛЬ ГУСТОЙ — куе кузгалак
ЩАВЕЛЬ ДОМАШНИЙ — йорт кузгалагы
ЩАВЕЛЬ ЗАЯЧИЙ — куян кузгалагы
ЩАВЕЛЬ КОНСКИЙ — ат кузгалагы (дару үсемлеге)
ЩАВЕЛЬ КУРЧАВЫЙ — бөдрә кузгалак
ЩАВЕЛЬ КРАСНЫЙ — кызыл кузгалак
ЩАВЕЛЬ МАЛЫЙ — чыпчык кузгалагы
ЩАВЕЛЬ ОБЫКНОВЕННЫЙ — эре кузгалак, гади кузгалак
ЩАВЕЛЬ ПРИБРЕЖНЫЙ — яр кузгалагы, эт кузгалагы
ЩАВЕЛЬ УЗКОЛИСТНЫЙ — тар яфраклы кузгалак
ЩЕБРУШКА ПОЛЕВАЯ — киек мәтрүшкәсе
ЩЕТИННИК ЗЕЛЁНЫЙ — яшел тычкан тарысы, яшел кыллы башак
ЩЕТИННИК СИЗЫЙ — күгелҗем тычкан тарысы
ЩИРИЦА ЗАПРОКИНУТАЯ — песи тарысы, песи койрыгы, кара алабута
ЩИРИЦА СИНЕВАТАЯ — зәңгәрсу песи тарысы
ЩИТОВНИК МУЖСКОЙ — ата абага
ЩУЧКА ДЕРНИСТАЯ *(луговик дернистый)* — болын солысы, елан теле

## Э

ЭВКАЛИПТ — эвкалипт (агач)
ЭВРИОЛА — эвриола (төнбоекчалардан)
ЭВТРОФНЫЕ РАСТЕНИЯ — эвтроф үсемлекләр
ЭДЕЛЬВЕЙС — эдельвейс (тау чәчәге)
ЭДИФИКАТОРЫ — эдификаторлар (фитоценозда күпчелек булып, аның "йөзен" билгеләүче үсемлекләр)
ЭКЗОДЕРМА — экзодерма (беренчел кайрының тышкы катлам күзәнәкләре)
ЭЛИЗАНТА НОЧЕЦВЕТНАЯ — төнчәчәкле элизанта
ЭЛИМУС *(овес песчаный)* — комлык солысы
ЭЛОДЕЯ КАНАДСКАЯ — Канада элодеясы, бака ефәге
ЭНЕРГИЯ ПРОРАСТАНИЯ — шыту энергиясе

ЭНДОСПЕРМ — эндосперм (серкәләнгәннән соң үсемлекләр орлыгында запас туплаучы тукыма)
ЭПИДЕРМИС — эпидермис (үсемлекләрнең тышкы каплам тукымасы)
ЭПИФИТЫ — эпифитлар (паразитлык итмичә, башка үсемлекләргә урнашып үсүче үсемлекләр)
ЭСКУЛАПОВА ТРАВА *(ластовень лекарственный)* — дарулы мамыкбаш
ЭСПАРЦЕТ — эспарцет
ЭФЕДРА ДВУХКОЛОСКОВАЯ — башаклы кызыл тамыр, тау тамыры
ЭФЕМЕРОИДЫ — эфемероидлар (бик кыска вегетацияле күпьеллык үсемлекләр)
ЭФЕМЕРЫ — эфемерлар (бик кыска вегетацияле берьеллык үсемлекләр)

## Ю

ЮККА — юкка (мәңге яшел үсемлекләр)

## Я

ЯБЛОНЯ — алмагач
ЯВОР *(белый клён)* — ак өрәңге, ак чаган
ЯГЕЛЬ *(олений мох)* — болан мүге
ЯГОДА — җиләк
ЯГОДА ВИННАЯ *(фига)* — инҗир җимеше
ЯЗВЕННИК МНОГОЛИСТНЫЙ — күп яфраклы куян кәрешкәсе
ЯРУТКА ПОЛЕВАЯ — кыр яруты, шылдыравык үлән
ЯСЕНЬ — корыч агач, дардар агачы
ЯСКОЛКА ДЕРНИСТАЯ — ешкул, дала ешкулы
ЯСМЕННИК КРАСИЛЬНЫЙ — буяу сырмавыгы
ЯСМЕННИК ПАХУЧИЙ — исле сырмавык
ЯСМЕННИК ШЕРОХОВАТЫЙ — кытыршы сырмавык
ЯСМЕННИК ЦЕПКИЙ — ябышкак сырмавык
ЯСНОТКА — баллут, сукыр кычыткан
ЯСНОТКА БЕЛАЯ — сукыр кычыткан, ак баллут
ЯСНОТКА КРАПЧАТАЯ — тимгелле баллут
ЯСНОТКА НАДРЕЗНАЯ — теленмә баллут
ЯСНОТКА ПУРПУРОВАЯ — кызгылт баллут
ЯСНОТКА СТЕБЛЕОБЪЕМЛЮЩАЯ — сабак кочар баллут
ЯСТРЕБИНКА ВОЛОСИСТАЯ — төкле карчыга үләне, тырнак уты
ЯСТРЕБИНКА ЗОНТИКОВИДНАЯ — тырнак үлән, чатырсыман карчыга уты
ЯСТРЕБИНКА ИЗОГНУТОЗУБЧАТАЯ — карчыга үләне, пычкы яфраклы карчыга үләне
ЯСТРЕБИНКА КРАСИВОЗУБЧАТАЯ — тырнак уты, кырлы яфраклы карчыга уты
ЯСТРЕБИНКА ЛУГОВАЯ — болын карчыга үләне
ЯСТРЕБИНКА ОБМАНЧИВАЯ — ялган карчыга уты
ЯСТРЕБИНКА ЯДОВИТАЯ — агулы карчыга үләне
ЯТРЫШНИК — төер тамыр, күке яше
ЯТРЫШНИК КРОВАВЫЙ — канлы төер тамыр
ЯТРЫШНИК МЯСОКРАСНЫЙ — кызыл төер тамыр, кызыл сәхләб
ЯТРЫШНИК ОБОЖЖЁННЫЙ — көйгән төер тамыр
ЯТРЫШНИК ПЯТНИСТЫЙ — тимгелле төер тамыр
ЯТРЫШНИК ШЛЕМОВИДНЫЙ — башлыксыман төер тамыр
ЯЧМЕНЬ — арпа
ЯЧМЕНЬ ДВУРЯДНЫЙ — ике рәтле арпа
ЯЧМЕНЬ ДИКИЙ — арпаган (чүп үлән)
ЯЧМЕНЬ ЛУКОВИЧНЫЙ — суганчалы арпа
ЯЧМЕНЬ МНОГОРЯДНЫЙ — күп рәтле арпа
ЯЧМЕНЬ ЯРОВОЙ — язгы арпа
ЯЧМЕНЬ ГРИВАСТЫЙ — озын кылчыклы арпа

## Грибы

### А

АГАРИКОВЫЕ (*пластинчатые*) ГРИБЫ— җәймәле гөмбәләр
АСКОМИЦЕТЫ (*сумчатые грибы*) — аскомицетлар (сумкалы гөмбәләр)
АСКОСПОРЫ — аскомицетларның үрчү споралары

### Б

БАЗИДИОМИЦЕТЫ — базидиаль гөмбәләр
БАЗИДИИ — базидияләр (гөмбәләрнең үрчү органнары)
БЕЛЫЙ ГРИБ — ак гөмбә
БЕЛЫЙ ГРИБ БЕРЁЗОВЫЙ — каенлык ак гөмбәсе
БЕЛЫЙ ГРИБ БОРОВИК — наратлык ак гөмбәсе
БЕЛЫЙ ГРИБ ДУБОВЫЙ — имәнлек ак гөмбәсе
БЕЛЫЙ ГРИБ ЕЛОВЫЙ — чыршылык ак гөмбәсе
БЕЛЫЙ ГРИБ ЛОЖНЫЙ — ялган ак гөмбә
БЕЛЫЙ ГРИБ ОСИНОВЫЙ — усаклык ак гөмбәсе
БЛЮДЦЕВИК ЖИЛКОВАТЫЙ — сеңерчәле тәлинкә гөмбә
БОРОВИК — нарат гөмбәсе
БОРОВИК НЕСЪЕДОБНЫЙ — наратлык агулы ак гөмбәсе
БУЛАВНИЦА — чукмарбаш гөмбә

### В

ВАЛУЙ — валуй
ВЕСЕЛКА ОБЫКНОВЕННАЯ — куандыргыч гөмбә
ВЕШЕНКА ОБЫКНОВЕННАЯ — гади яз гөмбәсе
ВЕШЕНКА РОЖКОВИДНАЯ — мөгезсыман яз гөмбәсе
ВОЛНУШКА (*волнуха*)— кызыл гөмбә, йөнтәс гөмбә
ВОЛНУШКА РОЗОВАЯ — алсу йөнтәс гөмбә
ВОЛОКОННИЦА ЗЕМЛЯНАЯ — җепселле җир гөмбәсе



### Г

ГАСТЕРОМИЦЕТЫ — гастеромицетлар
ГИМЕНИЙ — гимений (гөмбәләрдә үрчү өлешләренең споралы катламы)
ГИМЕНОФОР — гименофор (базидиомицетларның үрчү өлешендәге гименийлы катлавы)
ГИФЫ — гифлар (гөмбә җепселләре йомгагы)
ГЛАДЫШ (*гриб молочай*) — шома гөмбә
ГОВОРУШКА СЕРАЯ — соры говорушка, соры лыгырдык гөмбә
ГОЛОВАЧ КРУГЛЫЙ — түгәрәкбаш
ГОЛОВНЕВЫЕ ГРИБЫ — кисәү гөмбәләр, корымбашлар
ГРИБ-БАРАН — тәкә гөмбә
ГРИБ ЕЖЕВИК — бөрлегән гөмбә
ГРИБ-ЗОНТИК БЕЛЫЙ — ак чатыр гөмбә
ГРИБНИЦА (*мицелий*) — гөмбәлек
ГРУЗДЬ ДУБОВЫЙ — имән гөреҗдәсе
ГРУЗДЬ ЖЕЛЧНЫЙ — үтле гөреҗдә
ГРУЗДЬ ЖЁЛТЫЙ — сары гөреҗдә
ГРУЗДЬ НАСТОЯЩИЙ — чын гөреҗдә
ГРУЗДЬ ПЕРЕЧНЫЙ — борыч гөреҗдә
ГРУЗДЬ СИНЕЮЩИЙ — зәңгәрләнүчән гөреҗдә
ГРУЗДЬ ЧЁРНЫЙ — кара гөреҗдә

### Д

ДИСКОМИЦЕТЫ — дискомицетлар
ДОЖДЕВИК ГИГАНТСКИЙ — зур куык гөмбә, саңгырау гөмбә
ДОЖДЕВИК КРАПЧАТЫЙ — чуар куык гөмбә
ДОЖДЕВИК ЛОЖНЫЙ — ялган куык гөмбә
ДОМОВЫЙ ГРИБ — бүрәнә гөмбәсе
ДРОЖЖЕВЫЕ ГРИБЫ — чүпрә гөмбәләре
ДУБОВИК КРАПЧАТЫЙ — чуар имән гөмбәсе
ДУБОВИК ОБЫКНОВЕННЫЙ — гади имән гөмбәсе

### Е

ЕЖОВИК ЖЁЛТЫЙ — сары керпе гөмбә
ЕЖОВИК ПЁСТРЫЙ — чуар керпе гөмбә

ЕЖОВИК ШЕРСТИСТОНОГИЙ — төкле саплы керпе гөмбә
ЕЛОВИК ЖЁЛТЫЙ — сары чыршы гөмбәсе

## Ж

ЖЕЛЧНЫЙ ГРИБ — үтле гөмбә

## З

ЗАЯЧЬЕ УШКО — куянколак
ЗЕЛЕНУШКА *(рядовка зелёная)* — яшел гөмбә, яшел рядовка
ЗООСПОРАНГИЙ — гөмбәләрдә орлыклар ясалу-үсү урыны

## К

КАРТОФЕЛЬНЫЙ ГРИБ — бәрәңге гөмбәсе
КАШТАНОВЫЙ ГРИБ — кәстәнә гөмбәсе
КОЗЛЯК — кәҗәкәй гөмбә
КОЛПАК КОЛЬЧАТЫЙ — боҗралы калфак
КРАСНУШКА — кызылкай

## Л

ЛИСИЧКА ЖЁЛТАЯ — сары әтәч гөмбәсе
ЛИСИЧКА ЛОЖНАЯ — ялган әтәч гөмбәсе
ЛИСИЧКА НАСТОЯЩАЯ — чын әтәч гөмбәсе
ЛОЖНОДОЖДЕВИК ОБЫКНОВЕННЫЙ — ялган куык гөмбә
ЛОЖНООПЁНОК СЕРОПЛАСТИНЧАТЫЙ — ялган соры баллы гөмбә
ЛОЖНЫЙ ВАЛУЙ — ялган валуй

## М

МАСЛЁНОК БОЛОТНЫЙ — саз майлы гөмбәсе
МАСЛЁНОК ЗЕРНИСТЫЙ — ярмалы майлы гөмбә
МАСЛЁНОК ЛИСТВЕННИЧНЫЙ — карагай майлы гөмбәсе
МАСЛЁНОК НАСТОЯЩИЙ — майлы гөмбә
МИКОЛОГИЯ — гөмбәләрне өйрәнүче фән
МИКОРИЗА — гөмбә-тамыр



МЛЕЧНИК ОБЫКНОВЕННЫЙ — сөтчел гөмбә
МОКРУХА ЕЛОВАЯ — юеш чыршы гөмбәсе
МОХОВИК ЖЁЛТО-БУРЫЙ — саргылт-көрән мүк гөмбәсе
МОХОВИК ЗЕЛЁНЫЙ — яшел мүк гөмбәсе
МОХОВИК КРАСНЫЙ — кызыл мүк гөмбәсе
МОХОВИК ПЁСТРЫЙ — чуар мүк гөмбәсе
МУКОР — ак күгәрек (гөмбә)
МУКОР ГОЛОВЧАТЫЙ — башсыман күгәрек гөмбә
МУХОМОР — чебен гөмбәсе
МУХОМОР ВОНЮЧИЙ — сасы чебен гөмбәсе
МУХОМОР ЗЕЛЁНЫЙ *(поганка бледная)* — яшел чебен гөмбәсе, томсык гөмбә
МУХОМОР КРАСНЫЙ — кызыл чебен гөмбәсе
МУХОМОР ПАНТЕРНЫЙ — чуар чебен гөмбәсе
МУХОМОР ТОЛСТЫЙ — юан чебен гөмбәсе

## Н

НАВОЗНИК — тирес гөмбәсе
НАВОЗНИК БЕЛЫЙ — ак тирес гөмбәсе
НАВОЗНИК МЕРЦАЮЩИЙ — җемелдек тирес гөмбәсе
НАВОЗНИК СЕРЫЙ — соры тирес гөмбәсе

## О

ОЛЕНИЙ ГРИБ — болан гөмбәсе
ООСПОРА — оомицетларның тын споралары
ОПЁНОК КИРПИЧНО-КРАСНЫЙ ЛОЖНЫЙ — ялган кызыл баллы гөмбә
ОПЁНОК ЛЕТНИЙ — җәйге баллы гөмбә
ОПЁНОК ЛОЖНЫЙ СЕРНО-ЖЁЛТЫЙ — күкертләй сары ялган баллы гөмбә
ОПЁНОК ЛУГОВОЙ — болын баллы гөмбәсе
ОПЁНОК ОСЕННИЙ — көзге баллы гөмбә

## П

ПАУТИННИК КОРИЧНЕВЫЙ — пәрәвезле көрән гөмбә
ПЕРЕЧНЫЙ ГРИБ — борычлы гөмбә
ПЛЕСНЕВЫЕ ГРИБЫ — күгәрек гөмбәләр

ПОГАНКА БЛЕДНАЯ (*мухомор зелёный*) — аксыл томсык гөмбә
ПОГАНКА ЖЁЛТАЯ — сары томсык гөмбә
ПОДБЕРЁЗОВИК ОБЫКНОВЕННЫЙ — каен гөмбәсе
ПОДБЕРЁЗОВИК БОЛОТНЫЙ — саз каен гөмбәсе
ПОДГРУЗДОК БЕЛЫЙ — ак гөреҗдә
ПОДГРУЗДОК ЧЁРНЫЙ — вак кара гөреҗдә
ПОДДУБНИК — имән гөмбәсе
ПОДОСИНОВИК — усак гөмбәсе
ПОДОСИНОВИК ЖЁЛТО-БУРЫЙ — саргылт-көрән усак гөмбәсе
ПОДОСИНОВИК КРАСНЫЙ — кызыл усак гөмбәсе
ПОПЛАВОК СЕРЫЙ — соры калкавыч

## Р

РЖАВЧИННЫЕ ГРИБЫ — тутык гөмбәләр
РОГАТИК ЖЁЛТЫЙ — мөгезле сары гөмбә
РЫЖИК — җирән гөмбә
РЫЖИК ЕЛОВЫЙ — чыршы җирән гөмбәсе
РЫЖИК КРАСНЫЙ — кызгылт җирән гөмбә
РЫЖИК СОСНОВЫЙ — нарат җирән гөмбәсе
РЯДОВКА СЕРАЯ — соры рядовка
РЯДОВКА ТОПОЛЕВАЯ — тирәк рядовкасы
РЯДОВКА ФИОЛЕТОВАЯ — шәмәхә рядовка

## С

САТАНИНСКИЙ ГРИБ — шайтан гөмбәсе
СВИНУШКА — дуңгыз гөмбәсе
СЕРУШКА — сорыкай гөмбә
СИНЯК — күк гөмбә
СКЛЕРОЦИЙ — кайбер гөмбәләрдә кышлап үрчү өчен җепсел-ләрнең тыгыз укмашуы
СКРИПИЦА — шыгырдавык гөмбә
СЛИЗЕВИКИ (*миксомицеты*)— лайлач гөмбәләр (*миксомицетлар*)
СМОРЧОК ВОНЮЧИЙ — җир мае, сасы җыерчыклы гөмбә, сасы кәҗә гөмбәсе
СМОРЧОК КОНУСОВИДНЫЙ — очлы җыерчыклы гөмбә, очлы кәҗә гөмбәсе
СМОРЧОК НАСТОЯЩИЙ — чын җыерчыклы гөмбә, чын кәҗә гөмбәсе



СПОРЫНЬЯ ПУРПУРНАЯ — җете кызыл арыш анасы
СТРОЧОК ОБЫКНОВЕННЫЙ — җөйле гөмбә
СУМЧАТЫЕ ГРИБЫ (*аскомицеты*) — сумкалы гөмбәләр (*аско-мицетлар*)
СЫРОЕЖКА — ал гөмбә
СЫРОЕЖКА ЗЕЛЕНОВАТАЯ — яшькелт эшләпәле ал гөмбә
СЫРОЕЖКА ЛОМКАЯ — уалучан ал гөмбә

## Т

ТЕЛЕЙТОСПОРА — тутык гөмбәләр спораларының бер төре
ТРУБЧАТЫЕ ГРИБЫ — көпшәле гөмбәләр
ТРУТОВИК — агач гөмбәсе, ку гөмбәсе
ТРУТОВИК ЛОЖНЫЙ — ялган агач гөмбәсе
ТРУТОВИК НАСТОЯЩИЙ — чын агач гөмбәсе, чын ку гөмбәсе
ТРЮФЕЛЬ БЕЛЫЙ — ак томалан
ТРЮФЕЛЬ ОЛЕНИЙ — болан гөмбәсе

## У

УРЕДОСПОРА — тутык гөмбәләрнең җәйге споралары

## Ф

ФИТОФТОРА — үсемлекләр авыруын китереп чыгаручы гөмбә-ләр ыругы

## Ч

ЧАГА — кара каен гөмбәсе
ЧЕРНУШКА — кара гөмбә
ЧЕСНОЧНИК МАЛЫЙ — сарымсакча вак гөмбә
ЧЕСНОЧНЫЙ ГРИБ — сарымсак исле гөмбә

## Ш

ШАМПИНЬОН ЛЕСНОЙ — урман шампиньоны
ШАМПИНЬОН ПОЛЕВОЙ — кыр шампиньоны
ШЛЯПОЧНЫЕ ГРИБЫ — эшләпәле гөмбәләр

## КОЯШ НУРЛАРЫНДА НАЗЛАНА ИРКӘ ГӨЛЛӘР, ҮЛӘННӘРНЕ СЫЙПАП УЗА ТАЛГЫН ҖИЛЛӘР

Мин бала чакта җәйләрен балтырган, какы, гәзнич... ашап үстем. Мәктәп елларында үзебезнең авыл кырларында, инеш буйларында һәм урманнарда балкып чәчәк атып утырган үсемлекләрне күзәтә, гербарийлар хәзерли идем. Бу минем өчен бик тә кызыклы һәм мавыктыргыч шөгыль булды. Шунда, үзем дә сизмәстән, яфрак-чәчәкләр белән сөйләшә торган булып киттем. Мине табигатьтәге һәрнәрсә сокландыра иде. Алай гынамы соң, алар үзләрендә яшеренеп яткан серләре белән күңелемне биләделәр. Тора-бара үсемлекләр дөньясында үзем өчен ачышлар ясый башладым. Хәзер дә бу өлкәдә мине кызыксындырган нәрсәләр күп: балачактан килгән эзләнүләремне дәвам иттерәм, тәҗрибәләр ясыйм, күзәтүләр алып барам.

Шулай дигәннән, мин сезгә энҗе чәчәкләр (ландыш) белән үткәргән бер тәҗрибәм хакында сөйлим әле. Май аенда үсеп чыгып, тирә-юньгә хушбуй исләрен таратып утырган бу урман үсемлеген белмәгән кеше юктыр. Моннан берничә ел элек көзен, октябрь ае ахырында, ике төп энҗе чәчәген туфрагы белән бергә төпләп, өйгә алып кайттым. Алар нәни генә ак бәбәкләрен дә төрткән иде. Димәк, энҗе чәчәкләр кара көздән үк киләсе язга әзерләнә икән. Мин, тамырларны ипләп, юеш чүпрәккә төрдем дә аларны салкынча урынга чыгарып куйдым.

Бер ай үткәч, тамырларны чүлмәкләргә утыртып, аларны тәрәзә төбенә тездем. Атна чамасы вакыт үтүгә ландышларым ап-ак борыннарын төртте. 6—7 сантиметрга җитеп үскәнчегә кадәр, аларга җылы (+25 °С) су сибеп тордым. Гөлләрем көнләп түгел, сәгатьләп үстеләр.

Яңа елга бер-ике генә көн калып бара иде. Бәйрәмне сизенгәндәй, урман гөлләрем җептәй нечкә сабакларында асылмалы нәни кыңгыраучыкка охшаган энҗе чәчәкләрен күрсәтте. Бүлмәгә хуш исләрен бөркеп, тәрәзә төбендә Яңа елны каршыламасынмы ландышларым! Могҗиза бит бу! Белсәгез иде шул сәгатьләрдә нинди уйлар, ләззәтле хисләр кичергәнемне?! Безнең гаиләгә Табигатьнең чын Яңа ел бүләге иде бит бу!



Сынап карагыз әле: бәлки сезгә дә Табигать шундый күркәм бүләк әзерләгәндер.

Бу тәҗрибә минем күңелемне үстереп җибәрде, кыр үләннәрен бакчамда үстереп карау нияте туды. Моннан дистә еллар чамасы элек, көзен, туган авылым урманнарыннан зәңгәр кыңгырау, сары умырзая тамырларын төпләп һәм чебен үләненең орлыкларын җыеп, Казанга алып кайткан идем. Аларны Казан ягы климатик шартларында, көлсу туфракта үстереп карау минем өчен кызык иде. Чөнки әлеге үсемлекләр Татарстанның көньяк-көнчыгыш җирләрендә үсәргә яраклашканнар. Җитмәсә, сары умырзая Казан ягында һәм аңа якын төбәкләрдә гомумән очрамый, ул — үз төбәгендә дә сирәк үсемлек.

Ничек кенә булмасын, теләгемә ирештем. Хәзер, ел саен, май аенда сары умырзая — алтын, "кыңгырау"ларым зәңгәр чәчәкләре белән бакчамны бизиләр, чәчәкләре елдан-ел эреләнә бара. Соңгысы, өч-дүрт ел эчендә ишәеп китеп, бөтен бакчамны басты, хәтта күршеләрем бакчасына да "атлады". Алар урманныкына караганда, күбрәк чәчәк аталар. Чебен үләне дә зур булып үсте; июль ахырында, август башында түм-түгәрәк кызыл төймә-җимешләре белән чибәрләнеп утыра.

Бу үсемлекләр турында сүз чыккач, шунысын да әйтим: сары умырзая (ул агулы) һәм чебен үләне (бусыннан ризыклар да әзерлиләр) медицинада кыйммәтле дару чималы булып санала.

Андызны безнең республикада Минзәлә, Спас һәм Тәтеш районнарының кайбер авыллары тирәсендәге җирләрдә генә үсә, диләр. Ул да бакчамны үз итте. Хәер, миндәгенәме соң, аны хәзер күп бакчачылар үстерә. Бу үсемлек тә файдалы — аны төрле ашамлыкларга кушалар, күп чирләрдән дәва.

Ә менә сезнең виноград үстереп карарга теләгегез юкмы? Татарстанда хәзер аның төрле сортларын үстерәләр. Мин дә шулай, кызыгып китеп, виноградның "Тукай" һәм "Әмирхан" дигән сортларын юнәттем. Аларның чыбыкчаларын миңа Алтай краеның Бийск шәһәрендә яшәүче селекционер җибәргән иде. Ул үзе бу сортларны Донбасстан алып кайткан булган. Кырыс табигатьле Себер җиренә ияләштергән ул бу виноградларны, еллар үтү белән алардан мул уңыш үстереп алуга ирешкән. Мин дә әлеге чыбыкчаларны утыртуымның өченче көзендә беренче уңыш алдым.

Урман винограды турында ишеткәнегез бармы сезнең?

Артышны (арча) шулай да атыйлар. Ул — мәңге яшел һәм ылыслы куак-агач, кипарисчалар семьялыгына карый, ылыслы урманнарда төркем-төркем булып үсә. Артыш — озын гомерле үсемлек — 300 ел яшәгәннәрен очратырга мөмкин, Тянь-Шань таулары урманнарында 500 еллыклары бар. Аның күркә-җимешләре, чәчәк атканнан соң, икенче елның көзенә өлгерә. Алар эфир маена, шикәр, сумала, төрле кислота һәм башка матдәләргә бай. Аның җимешләре төрле сырхауга дәва буларак файдалы, азык промышленностенда кулланыла.

Артышның тагын бер өстенлеге бар. Ул һавага фитонцидлар бүлеп чыгара, ә алар кеше өчен бик файдалы. Әйе, кумәкләшеп үсә торган бу куаклар — табигатьнең саф һава лабораториясе. Бер гектар мәйданда үсеп утырган шундый хәзинә тәүлек буенча 30 килограмм файдалы матдә бүлеп чыгара һәм тирә-юньне сафландыра. Бу исә зур бер шәһәрне зарарлы бактерияләрдән арындырырга җитәр иде. Шуңа күрә артышны кала бакчаларында һәм газоннарында, авыл бакчаларында үстереп карасак, бик тә файдалы эш башкарыр идек. Мәктәп укучыларының бу изге эшкә алынуы бик хуп булыр иде.

Җәен һәркем табигать кочагына омтыла. Сине урманда яки болында елмаешып утырган чәчәкләр каршылый. Җан рәхәте кичерәсең, күкрәк киереп саф һавасын сулыйсың. Чәчәкләр басу-кырларда да аз түгел. Әнә, диңгездәй дулкын каккан арыш арасында да зәңгәр чәчәкләр (күкбашлар) сибелгән. Күкбаш матур чәчәк кенә түгел, ул — дару үләне дә. Бу нәфис үсемлекнең тагын бер сыйфаты бар. Аның чәчәкләреннән зәңгәр буяу алып, тукымаларны маналар.

Зәңгәр чәчәк (сука чәчәге дә диләр) орлыкларын август аенда өлгертә. Алар арыш бөртегенә охшаган. Орлыкның бер очында йонлач "бүрекчеге" бар. Ул үсемлеккә әйбәт үсү өчен уңдырышлы туфракны эзләп табарга ярдәм итә. Әлеге "бүрекчек" юешләнсә, йоннары кыскара, коры булганда озыная. Шулай итеп, орлык "аяклана" — үрмәләп барып, үзенә кирәкле туфракны таба. Зәңгәр чәчәкнең шундый хикмәте, шундый сере бар.

Синең бөҗәк ашаучы үсемлекләр турында ишеткәнең бармы? Алар турында тропик урманнарда гына үсә, дигән фикердә торучылар да бар. Андый үләннең бер вәкиле безнең якта да, сазлыктагы мүк түмгәкләре өстендә үсә. Ул — чыклы үлән, буе нибары 10 — 15 сантиметр гына. Яфраклары вак бөҗәкләрне (әйтик, черки) тоту өчен төкчәләр белән капланган. Бу үләнне сөялләрне бетерү, салкын тигәндә ютәлне басу, тир чыгару өчен файдаланалар.



Орхидеяләр шулай ук Һиндстан һәм Бразилиянең тропик урманнарында гына түгел, безнең урманнарда да үсә. Дөрес, әлеге илләр тропикларында алар дистәләрчә төрдә һәм рәвештә, чәчәкләре гаҗәеп матур төсләргә манчылган булса, безнең урманнарда үскәннәре үзләренең гүзәллеге белән күзгә әллә ни чагылмыйлар. Шундыйлардан мин күке яшен, төер тамыр, төнге миләүшәне әйтер идем.

Кечкенә генә язмада бинеһая чуар үсемлекләр дөньясы турында сөйләп бетерү мөмкин түгел. Элек үсемлекләр рәтендә йөртелеп, хәзер аерым патшалык итеп карала торган гөмбәләргә дә бик аз гына тукталам.

Гөмбәләр дөньясы да бай. Әйтик, галимнәр җир шарында гөмбәләрнең 100 мең чамасы төрен ачыклаганнар. Билгеле, алар арасында микроскоптан гына күренә торган гөмбәчекләр төр составы ягыннан күпчелекне тәшкил итә, гади күз белән күреп була торганнарының һәм шактый зурларының 7 меңләп төре исәпләнә. Шуларның 3 мең төре элекке СССР территориясенә туры килә. Идел буе җирләрендә 200 дән күбрәк ашарга яраклы гөмбә төре исәпләнә.

Билгеле, гөмбәләрнең агулы төрләре, ашарга яраксызлары күбрәк. Шуңа күрә урманның бу хәзинәсен җыйганда сак булыгыз, үзегез белмәгән гөмбәгә үрелмәгез!

**Касыйм ТӘХАУ**, журналистларның Х. Ямашев исемендәге республика премиясе лауреаты, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре.

## Нәшрияттан

Үсемлек атамаларында рус телендә, гадәттә, башта ыруг исеме, аннан соң төр исеме бирелсә, мәсәлән: *клевер луговой, вязь полевой*, татарчасында киресенчә бирелә, мәсәлән: *болын тукранбашы, кыр карамасы.*

Шунлыктан сүзлекнең татарча өлешеннән файдаланганда, үсемлек атамаларын ыруг исемнәре буенча түгел, бәлки төр исемнәре буенча эзләп табарга кирәк.

## Үсемлекләр

A

АБАГА — папоротник
АБАГА СПОРАНГИЙЛАРЫ ҖЫЕЛМАСЫ — сорус
АБАГАСЫМАННАР — папоротниковые
АБАКА *(банан төре)* — абака
АБРИКОС *(өрек агачы һәм җимеше)* — абрикос
АБРИКОС ТӨШЕ — абрикосовая косточка
АВОКАДО *(лавр, дәфнә агачы төре)* — авокадо
АВРАН ГӨЛЕ *(бизгәк үләне)* — авран лиственный
АВТОГАМЛЫЛЫК *(женси үрчү төре)* — автогамия
АВТОТРОФ ҮСЕМЛЕКЛӘР (органик булмаган матдәләр белән тукланалар) — автотрофные растения
АВЫЗЧЫК *(яфракларда)* — устьице
АВЫЗЧЫКЛАРНЫҢ ЯН КҮЗӘНӘКЛӘРЕ — побочные клетки устьиц
АГАВА *(тропик үсемлек)* — агава
АГАЧ БАШЫ — верхушка, макушка дерева
АГАЧ ГӨЛ *(фикус)* — фикус
АГАЧЧЫЛ ҮСЕМЛЕКЛӘР — растения деревянистые
АГАЧСЫМАН АБАГА — папоротник древовидный
АГУЛЫ КАЗАЯК — лютик ядовитый
АГУЛЫ ҮСЕМЛЕКЛӘР — растения ядовитые
АГУ УТЫ *(тимгелле түндербаш)* — болиголов крапчатый
АЕРЧА — лепесток
АЖДАҺА АГАЧЫ — драконово дерево
АЗАЛИЯ *(чәчәкле декоратив үсемлек)* — азалия
АЗОТ АЛУЧЫЛАР — азотопотребители
АЗОТ ҖЫЮЧЫЛАР — азотособиратели
АЗЫК НОГЫТЫ — корм бобовый
АЗЫКТАМЫР — корнеплод, корнеплодный
АЗЫК КӘБЕСТӘСЕ — капуста кормовая
АЗЫК ЧӨГЕНДЕРЕ — свёкла кормовая
АЙБАГАР — подсолнух, подсолнечник



АЙВА *(агачы һәм җимеше)* — айва
АЙРАВЫК — пырей обыкновенный
АЙЧӘЧӘК *(тырнаклы гөл)* — ноготки, календула
АК АКАЦИЯ *(ак сәрви)* — акация белая
АК АЛАБУТА *(ак онлыча)* — марь белая
АКБУР СЫРАҖЫ — норичник меловой
АК ЗЕЛПЕ — жимолость белая
АК КАЕН — берёза белая
АК КЫРЧЫЛ *(ак сусән)* — полевица белая
АК КӘБЕСТӘ — капуста белокочанная
АКСЫЛ КУЯН ЙОНЫ — ожика бледная
АКСЫЛ ЧӘЧӘКЛЕ ШОМБИА — заразиха бледноцветковая
АКСЫРГАК — чемерица
АК ТАЛ — верба белая, ива белая, ветла
АК ТАМЫР — пырей
АК ТИРӘК — тополь серебристый
АК ТОРМА — редька огородная
АК ТУКРАНБАШ — клевер белый
АК ТӘКӘМӨГЕЗ *(кандала үләне)* — донник белый
АК ТӨНБОЕК — кувшинка белая
АК ЧЕРЕМЧЕЛ *(күке төкереге)* — дрема белая
АК ЧАРГӨЛ *(көмешсыман тәпичә)* — лапчатка серебристая
АК ЧЫРШЫ — пихта
АК ЧЫРШЫЛЫК — пихтовник
АК ЧӘЧӘК — ромашка
АК ӘНИС — тмин обыкновенный
АК ӘРЕМ *(ачы әрем)* — полынь белая (горькая)
АК ӨРӘҢГЕ — клён белый
АК ҺИНДЫБА — цикорий белый
АК МҮК *(торф мүге)* — мох сфагнум
АЛАБАЙ *(сары шепкән, буяу чәчәге)* — пупавка красильная
АЛАБУТА — лебеда
АЛАБУТАЛЫК — заросли лебеды
АЛА МИЛӘҮШӘ — анютины глазки
АЛАН — лесная поляна
АЛАРИЯ *(суүсем)* — алария
АЛИССУМ *(хуш исле үсемлек)* — алиссум, каменник, бурачок
АЛКАГӨЛ — фуксия
АЛКА ЧӘЧӘК — серёжка (соцветие)
АЛМАГАЧ— яблоня

АЛМАГАЧТАЙ ГӨЛӘП — шиповник яблонный
АЛМАЛАНУ — появление завязи
АЛМА ҮЛӘНЕ — кирказон обыкновенный
АЛМАШ ЯФРАКЛЫ ТАЛАК ҮЛӘНЕ — селезёночник очереднолистный
АЛОЙ, ШЕШ ГӨЛЕ *(дару үсемлеге)* — алоэ
АЛТЫН КАМЧЫ *(алтын таяк)* — золотая розга, золотарник
АЛТЫ ТАҖ ЯФРАКЛЫ КУРА *(җир чикләвеге)* — таволга шестилепестная, земляной орех
АЛЬГОЛОГИЯ *(суүсемнәрне өйрәнүче фән)* — альгология
АМАРИЛЛИС *(суганчалы үсемлек)* — амариллис
АМЕРИКА ЧАГАНЫ — клён ясенелистный, американский
АНА АБАГА — кочедыжник женский
АНА МӘЧЕ БӨТНЕГЕ — котовник кошачий
АНА ЧӘЧӘК — цветок женский
АНЕМОФИЛИЯ *(җил ярдәмендә серкәләнү)* — анемофилия
АНЕМОХОРИЯ *(орлыкларның җил ярдәмендә таралуы)* — анемохория
АНТОЦИАН *(күзәнәктә төсле матдәләр)* — антоциан
АНТРОПОХОРИЯ *(җимешләрнең кеше ярдәмендә таралуы)* — антропохория
АНЧАР *(агулы агач)* — анчар
АНҺУЗА *(дару үсемлек)* — анхуза
АП-АК ТӨНБОЕК — кувшинка чистобелая
АРАДАШ КАЕШКЫРАН *(арадаш корычтамыр)* — стальник промежуточный
АРАДАШ САЗЛАВЫК УТЫ — ситняг промежуточный
АРАЛАШ ЯФРАКЛЫ ГЕНТИАНА — горечавка перекрестнолистная
АРАУКАРИЯ *(агач)* — араукария
АРПА — ячмень
АРТИШОК *(яшелчә үсемлек)* — артишок
АРТЫК БӘБӘК — пасынок
АРЫШ АНАСЫ *(арышта гөмбә авыруы)* — спорынья
АРЫШ КЫНДЫРАГЫ — костёр ржаной
АСЫЛМА ТАМЫРЛАР — корни воздушные
АСЫЛ МЕҢЪЯФРАК *(ак мәтрүшкә)* — тысячелистник благородный
АТА АБАГА — щитовник мужской
АТАЛАНУ — оплодотворение
АТА ЧӘЧӘК — цветок мужской



АТА ҮСЕНТЕК *(абагада һ.б.)* — антеридий
АТЛАНДЫРЫШ ЯЛГАУ — прививка седлообразная
АТ НОГЫТЫ — боб конский
АТ КУЗГАЛАГЫ — щавель конский
АТ КӘСТӘНӘСЕ — каштан конский
АХШАМ МИЛӘҮШӘСЕ — вечерница
АЧЫ КАКЫ — свергубец
АЧЫ КАРДАМИН — сердечник горький
АЧЫЛМАС ҖИМЕШ — плод нераскрывающийся
АЧЫЛМАС ЧӘЧӘКЛЕЛӘР — клейстогамные цветки
АЧЫК ОРЛЫКЛЫ ҮСЕМЛЕКЛӘР — растения голосеменные
АШАМЛЫК БИЛЧӘН — бодяк съедобный
АШАМЛЫК ЯСМЫК — чечевица съедобная
АШ ЧӨГЕНДЕРЕ — свёкла столовая

## Б

БАБУНӘ ЧӘЧӘК *(ак чәчәк)* — ромашка
БАВЫР МҮКЛӘР — мхи печёночные
БАДАМ АГАЧЫ — миндаль, миндалевое дерево
БАДРАН *(гөлбадран)* — пижма, дикая рябина
БАДЫМҖАН — баклажан
БАДЬЯН ҮЛӘНЕ — анис звёздчатый, бадьян китайский
БАКА ЕФӘГЕ — водоросль
БАКА САКАЛЫ *(субуяр)* — водокрас
БАКА ТӘҢКӘСЕ — ряска
БАКА ЧИКМӘНЕ — бутерлак портулаковый
БАКА ЧЫРШЫСЫ *(чыршы үләне, су чыршысы)* — уруть
БАКА ЯЛТЫРАГЫ (*бака кугасы*) — ситник лягушачий
БАКА ЯФРАГЫ — подорожник
БАКА ЯФРАГЫСЫМАН КӘҖӘ КУЗГАЛАГЫ — частуха подорожниковая
БАКА ҮЛӘНЕ — лебеда душистая
БАКРА — куколь
БАКРА ГӨЛ — петуния
БАКЧА РӘЙХАНЫ — чабер садовый
БАКЧА ШАЙТАН ТАЯГЫ — чертополох огородный
БАЛАВЫЗ АГАЧЫ — восковик
БАЛАВЫЗ ЯФРАКЛЫ САЗ КУАГЫ — подбел многолистный

БАКЧА ЧИКЛӘВЕГЕ *(фундук)* — фундук
БАКЧА ШПИНАТЫ — шпинат огородный
БАКЧА ЯСМИНЕ — жасмин садовый
БАЛАН — калина
БАЛАНЛЫК — заросли калины
БАЛЛУТ *(сукыр кычыткан, баллы баба)* — яснотка
БАЛЛЫ БАБА — яснотка
БАЛЛЫК — нектарник
БАЛЛЫ КАКЫ — свербига восточная
БАЛЛЫ КУЗАК — цареградский стручок
БАЛЛЫ ЧЫК — медвяная роса
БАЛЛЫ ЧӘЧӘК — иван-да-марья
БАЛЛЫ ЯФРАК — ярмолист
БАЛЛЫ ҮСЕМЛЕКЛӘР — растения медоносные
БАЛТЫРГАН *(себер балтырганы)* — борщевик сибирский
БАЛТЫРГАН — борщевик
БАМИЯ *(ашамлык бамия)* — бамия
БАНАН — банан
БАОБАБ *(маймыл агачы)* — баобаб
БАРБАРИС — барбарис
БАРМАКЧЫК *(уймак чәчәк)* — наперстянка
БАСУ КЫРЛЫГЫ — торица полевая
БАСУ ЯУШАНЫ — вероника пашенная
БАТКАК КҮКЕРТ ҮЛӘНЕ — плаун топяной
БАТМАНЧЫК *(су чикләвеге)* — рогульник (водяной орех)
БАШАК — соцветие колос
БАШАК КЫЛЧЫГЫ — ость
БАШАКЛАНУ *(башак чыгару)* — колошение
БАШАКЛЫ БҮРЕ БӨРЕСЕ *(карга җиләге)* — воронец колосистый
БАШАКЛЫ КЫЗЫЛ ТАМЫР *(тау тамыры)* — эфедра двухколосковая
БАШАКЛЫ СУ ЧЫРШЫСЫ — уруть колосистая
БАШАКЛЫЛАР *(кыяклылар)* — злаковые
БАШКОРТ ЧИЯСЕ — вишня степная, дикая
БАШЛЫКСЫМАН ТӨЕР ТАМЫР — ятрышник шлемовидный
БАШЧА *(мәс., тукранбашта)* — соцветие головка
БАШ ЧЫГАРУ — выметывание
БАЯЛЫЧ *(баялыш)* — ива белая, тальник
БЕЗҮЛӘН — шильник
БЕР БҮЛБЕЛЕ КАШ УТЫ — бровник обыкновенный
БЕР КАБЫРЧЫКЛЫ САЗЛАВЫК УТЫ — ситняг одночешуйчатый



БЕР КАТЛЫ ЧӘЧӘК ТИРӘЛЕГЕ — околоцветник простой
БЕРКҮЗӘНӘКЛЕ ҮСЕМЛЕКЛӘР — растения одноклеточные
БЕР ОРЛЫКЛЫ ҖИМЕШЛӘР — односеменные плоды
БЕР ОРЛЫК ӨЛЕШЛЕЛӘР — односемядольные
БЕРЬЕЛЛЫК ЙОНЧА — мятлик однолетний
БЕРЬЕЛЛЫК НӘДЕРБАШ — чистец однолетний
БЕРЬЕЛЛЫК ҮЛӘННӘР — однолетние травы
БЕР ӨЙЛЕ ҮСЕМЛЕКЛӘР — растения однодомные
БЕР ҖЕНЕСЛЕ ЧӘЧӘК — цветок однополый
БЕТ УТЫ *(тычкан борчагы)* — горошек мышиный
БИЕК АНДЫЗ — девясил высокий
БИЕК АРЫСЛАН ТЫРНАГЫ — зюзник высокий
БИЕК АЮ ТАБАНЫ *(биек аю көпшәсе)* — борец высокий
БИЕК КАЧИМ *(пәри уты)* — качим высочайший
БИЕК МИЛӘҮШӘ — фиалка высокая
БИЕК РАЙГРАС *(айравык)* — райграс высокий
БИЕК СОЛЫЧА *(озын солыча)* — овсяница гигантская
БИЕК ТУРГАЙ ТАРЫСЫ — песчанка высокая
БИЕК ЧАЛГЫЧУТ — гулявник высокий
БИЕК ЯРМАБАШ — перловник высокий
БИЕК ӘРЕМ — полынь высокая
БИЛЧӘН — осот
БИЛЧӘН УТЫ *(шайтан таягы)* — чертополох курчавый
БИШЬЯФРАК — пятилистник, сабельник
БОДАЙ — пшеница
БОЛАН КҮЗЕ — ромашка непахучая
БОЛАН МҮГЕ — олений мох, ягель
БОЛАН ҮЛӘНЕ *(борыч үләне)* — кардария крупковая
БОЛЫН — луг
БОЛЫН АРЫШБАШЫ *(болын сүсәне)* — тимофеевка луговая
БОЛЫН ЙОНЧАСЫ — мятлик луговой
БОЛЫН КАНӘФЕРЕ — гвоздика луговая
БОЛЫН КАРДАМИНЫ — сердечник луговой
БОЛЫН КАРЧЫГА ҮЛӘНЕ — ястребинка луговая
БОЛЫН КЫРЛЫ БОРЧАГЫ *(сары кәрешкә)* — чина луговая
БОЛЫН КӘҖӘСАКАЛЫ — козлобородник луговой
БОЛЫН КҮГӘРЧЕН БҮРЕГЕ *(кырмыска орлыгы)* — марьянник луговой
БОЛЫН НАРАТБАШЫ — хвощ луговой
БОЛЫН РОМАШКАСЫ — нивяник обыкновенный, поповник
БОЛЫН СОЛЫЧАСЫ — овсяница луговая

БОЛЫН ТУКРАНБАШЫ — клевер луговой
БОЛЫН ТӨЙМӘБАШЫ — василёк луговой
БОЛЫН ТӨЛКЕКОЙРЫГЫ — лисохвост луговой
БОЛЫН ЧӘЕ — чай луговой
БОЛЫН ШАЛФЕЕ — шалфей луговой
БОЛЫН ЯРАНЫ — герань луговая
БОРАЙ — полба
БОРЧАК — горох
БОРЧАК КУЗАГЫ — стручок гороха
БОРЧАКСЫМАН ЧИНА — чина гороховидная
БОРЧА ҮЛӘНЕ — блошница
БОРЫЧ БӨТНЕК — мята перечная
БОРЫЧ — перец
БОТАК, ТАРМАК — ветвь, ветка
БОТАК — сук, сучок, ветка, ветвь
БОТРИДИЙ *(суүсем төре)* — ботридий
БОХАР КЫНАСЫ — бальзамин
БОХАР МИЛӘШЕ *(аю баланы, карга миләше)* — бузина
БОҖРАК *(чәчәк төркеме)* — мутовка
БОҖРАЛЫ СУ ЧЫРШЫСЫ — уруть мутовчатая
БОҖРАЛЫ ШАЛФЕЙ — шалфей мутовчатый
БУА МИЛӘҮШӘСЕ — фиалка прудовая
БУАР ҮСЕМЛЕКЛӘР — растения лианы
БУШ БАШАКЛЫЛЫК — пустоколосье
БУШ ЧӘЧӘК *(кысыр чәчәк)* — пустоцвет
БУЫН *(буынтык)* — узел
БУЫННАН ҮСҮ — рост интеркалярный
БУЫН АРАСЫ *(кыяклыларда)* — междоузлие
БУЫНТЫКЛЫ ТӨЛКЕКОЙРЫК — лисохвост коленчатый
БУЯУ КУАГЫ — дрок красильный
БУЯУ СЫРМАВЫГЫ — ясменник красильный
БУЯУ МАТДӘСЕ — пигмент
БУЯУ ЧӘЧӘГЕ *(сары чәчәк)* — пупавка красильная
БУЯУ ҮЛӘНЕ — марена красильная
БӘБКӘ ҮЛӘНЕ *(чирәме)* — птичья гречишка
БӘБРИЯ *(куак)* — розмарин
БӘБӘК *(яшь ботак)* — побег
БӘБӘНӘК — зародыш (үсемлекләрдә)
БӘКАМ АГАЧЫ — сандаловое дерево
БӘРХЕТ ГӨЛ — бархотка
БӘРӘҢГЕ — картофель



БӘРӘҢГЕ АЛМАСЫ — картофельный плод
БӘРӘҢГЕНЕҢ ҖИР АСТЫ САБАГЫ — столон
БӘРӘҢГЕ КҮЗЕ — глазок картофеля
БӘРӘҢГЕ КУТЫРЫ — картофельная парша
БӨДРӘ КУЗГАЛАК — щавель курчавый
БӨДРӘ КӘБЕСТӘ — брюссельская (цветная) капуста
БӨДРӘ СУ КӘБЕСТӘСЕ — рдест курчавый
БӨДРӘ ТАЛ — ива плакучая
БӨДРӘ ТӘҢКӘ ЯФРАК — манжетка волнистолистная
БӨЕРГӘН — жеруха, жерушник
БӨКЕ *(икенчел япма тукыма)* — пробка
БӨКЕ АГАЧЫ — пробковое дерево
БӨКЕ КАМБИЕ — камбий пробковый
БӨРЕДӘН ЯЛГАУ — прививка глазком
БӨРЕЛӘНЕП ҮРЧҮ — размножение почкованием
БӨРКЕТ КАНАТЫ — орляк
БӨРЕ ЯЛГАУ — окулировка
БӨРЕДӘН ҮРЧҮ — почкование
БӨРЕ БОТАК — отводок
БӨРЕ — почка
БӨТНЕК — мята
БҮЛБЕ — клубень
БҮЛБЕЛЕ КАЛИПСО — калипсо клубневая
БҮЛБЕЛЕ КЫР КИШЕРЕ — бутень клубненосный
БҮЛБЕЛЕ ҮСЕМЛЕКЛӘР — клубеньковые
БҮЛБЕЛЕ ЧОРМАЛЧЫК — чина клубненосная
БҮЛБЕЛЕ ТАМЫР — клубнеплод
БҮЛМӘ ГӨЛЕ — комнатный цветок
БҮРЕ АЯГЫ *(күкерт үләне)* — плаун
БҮРЕ КҮЗ *(мәрдәр агачы)* — бирючина, волчий глаз
БҮРЕ ТЫРНАГЫ — змеевик, горец
БҮРЕ УТЫ — перекати-поле
БҮРЕ ҖИЛӘГЕ *(бүре юкәсе)* — волчьи ягоды, волчье лыко

## В

ВАК БАКА ТӘҢКӘСЕ — ряска малая
ВАК ГӨЛҖИМЕШ — роза морщинистая
ВАК КЫР СУГАНЫ — гусиный лук малый
ВАК ОРЛЫКЛЫ ШЕПКӘН — рыжик мелкоплодный

ВАК САРУТ *(мамык үлән)* — бескильница расставленная
ВАК ТӨКЛЕ КҮЗ УТЫ — очанка коротковолосистая
ВАК ЧӘЧӘКЛЕ БӨТНЕК — мята мелкоцветковая
ВАК ЧӘЧӘКЛЕ ГАЛИНЗОГА — галинзога мелкоцветковая
ВАК ЧӘЧӘКЛЕ КАРДАМИН — сердечник мелкоцветковый
ВАК ЧӘЧӘКЛЕ КЫНА — недотрога мелкоцветковая
ВАК ЧӘЧӘКЛЕ КҮГӘРЧЕН КҮЗЕ — незабудка мелкоцветковая
ВАК ЯФРАКЛЫ ЮКӘ — липа мелколистная
ВАЛЕРИАН *(дару үләне)* — валериана лекарственная
ВАНИЛЬ *(тропик үсемлек)* — ваниль
ВЕГЕТАТИВ ҮРЧҮ — вегетативное размножение
ВЕНГР СИРЕНЕ — сирень венгерская
ВИКА *(торна, карга борчагы)* — горошек, вика
ВИРГИН ШОМЫРТЫ — черемуха виргинская
ВИСТЕРИЯ *(агаччыл үсемлек)* — вистерия

## Г

ГАБИТУС *(организмның тышкы күренеше)* — габитус
ГАДИ АЛАБУТА — лебеда татарская
ГАДИ АЛМА ҮЛӘНЕ — кирказон обыкновенный
ГАДИ АРТЫШ *(куагы һәм җимеше)* — можжевельник обыкновенный
ГАДИ АРЧАН *(мәңге яшел куак)* — вереск обыкновенный
ГАДИ АЮ ҖИЛӘГЕ *(гади аю баланы, аюколак)* — толокнянка, медвежье ушко
ГАДИ БАКРА *(чәчүлек бакрасы)* — куколь посевной
ГАДИ БАЛАН — калина обыкновенная
ГАДИ БОЛЫН ЧӘЕ — вербейник обыкновенный
ГАДИ БУМА ҮЛӘНЕ — жирянка обыкновенная
ГАДИ БӨРКЕТ КАНАТЫ *(кара абага)* — орляк обыкновенный
ГАДИ ГАМБӘР ҮЛӘНЕ — истод обыкновенный
ГАДИ ДАЛА ҖИТЕНЕ *(марҗа башмагы)* — льнянка обыкновенная
ГАДИ ДЕГЕТ ЧӘЧӘГЕ *(сагызлы чәчәк)* — смолка обыкновенная
ГАДИ ДЕГӘНӘК — мордовник обыкновенный
ГАДИ ЕЛАН КАМЫШЫ *(гади су нараты)* — хвостник обыкновенный
ГАДИ ЕЛАН ҮЛӘНЕ *(әңгерәк уты)* — синяк обыкновенный
ГАДИ КАБАК — тыква обыкновенная



ГАДИ КАРАБАШ — черноголовка обыкновенная
ГАДИ КЕРӘН — хрен обыкновенный
ГАДИ КИШЕР ҮЛӘНЕ *(гади кишерчә)* — морковник обыкновенный
ГАДИ КУРА ҖИЛӘГЕ — малина обыкновенная
ГАДИ КУЫК ЯФРАК — пузырчатка обыкновенная
ГАДИ КЫЛЫЧ ҮЛӘН — меч-трава обыкновенная
ГАДИ КЫМЫЗЛЫК — кислица обыкновенная
ГАДИ КҮПТАМЫР — многокоренник обыкновенный
ГАДИ МАРТА ЧӘЧӘГЕ *(гади күзлут)* — пикульник обыкновенный
ГАДИ МЕҢЪЯФРАК — тысячелистник обыкновенный
ГАДИ МӘТРҮШКӘ — душица обыкновенная
ГАДИ МҮК ҖИЛӘГЕ *(гади саз җиләге)* — клюква обыкновенная
ГАДИ НАРАТ — сосна обыкновенная
ГАДИ САЗ ЙОЛДЫЗЫ — болотник обыкновенный
ГАДИ САРУТ *(айравык)* — бекмания обыкновенная, пырей
ГАДИ СИРЕНЬ *(канәфер куагы)* — сирень обыкновенная
ГАДИ СУҖЫЯР — водосбор обыкновенный
ГАДИ СЫРЛАН — липучка обыкновенная
ГАДИ СӘРДӘ — сныть обыкновенная
ГАДИ СӨТЛЕ ВИЛЧӘН — бодяк обыкновенный
ГАДИ СӨЯЛ ҮЛӘНЕ — бородавник обыкновенный
ГАДИ ТАВЫК ҮЛӘНЕ — калужница обыкновенная
ГАДИ ТУЗГАКБАШ — крестовник обыкновенный
ГАДИ ТӘВӘ КАУРЫЕ — страусник обыкновенный
ГАДИ ТӘНКИСӘР *(кискеч кыяк)* — телорез обыкновенный
ГАДИ УКЪЯФРАК *(су угы)* — стрелолист обыкновенный
ГАДИ ФАСОЛЬ *(гади ногыт)* — фасоль обыкновенная
ГАДИ ӘНИС — анис обыкновенный
ГАДИ ЧЫРШЫ ҮЛӘНЕ — подъелник обыкновенный
ГАДИ ШАРТЛАВЫК ЧӘЧӘК — смолевка обыкновенная, хлопушка
ГАДИ ЭТ КАКЫСЫ *(бүдәнә кузагы)* — сурепица обыкновенная
ГАДИ ЭТ ТИГӘНӘГЕ — репешок обыкновенный
ГАДИ ЯЛАН КЫНАСЫ *(гади ялан рәйханы, исле чәчәк)* — пахучка обыкновенная
ГАДИ ҺИНДЫБА *(эт каешы)* — цикорий обыкновенный
ГАҖӘЕП МИЛӘҮШӘ — фиалка удивительная
ГЕТЕРОКАРПИЯ *(бер үсемлектә төрле генератив яралгылар ясалу күренеше)* — гетерокарпия

ГИБРИД АЛАБУТА — марь гибридная
ГЛАДИОЛУС *(кылыч гөл)* — гладиолус
ГЛЕДИЧИЯ *(агач)* — гледичия
ГОНҖӘ *(чәчәк бөресе)* — бутон, цветочная почка
ГОРТЕНЗИЯ *(япон гөле)* — гортензия
ГОРЧАК *(чүп үлән)* — горчак
ГОРЧИЦА *(майлы үсемлек)* — горчица
ГРАНАТ АГАЧЫ *(анар)* — гранатовое дерево
ГРУША — груша
ГӘЗНИЧ *(куян тубыгы)* — пастернак лесной
ГӘРӘҢКӘ *(төче торма, бүкән шалкан)* — брюква
ГӨБЕРЛЕ БАКА ҮЛӘНЕ *(куян йоны)* — жабник полевой
ГӨЛБАБА — кульбаба
ГӨЛБАДРАН — пижма обыкновенная
ГӨЛЧӘЧӘК *(роза)* — роза
ГӨЛҖИМЕШ *(гөләп)* — шиповник

## Д

ДАВЫЛ ЧӘЧӘГЕ — лютик едкий
ДАЛА АРЫШБАШЫ — тимофеевка степная
ДАЛАЛАШКАН ШАЛФЕЙ — шалфей остепнённый
ДАЛА ӘРЕМЕ — полынь равнинная
ДАРДАР АГАЧЫ *(корыч агач)* — ясень
ДАРУЛЫ КАРА ТАМЫР *(дару кырмавыгы)* — чернокорень лекарственный
ДАРУЛЫ КЫР САБЫНЫ — мыльнянка лекарственная
ДАРУЛЫ КЫЯР ҮЛӘНЕ — бурачник лекарственный
ДАРУЛЫ ЛЮБИСТОК — любисток лекарственный
ДАРУЛЫ МАМЫКБАШ — ластовень лекарственный
ДАРУЛЫ МЕЛИССА *(лимон исле бөтнек)* — мелисса лекарственная
ДАРУЛЫ МӘЧЕ БОРЧАГЫ — алтей лекарственный
ДАРУЛЫ ПЕСИ ҮЛӘНЕ — валериана лекарственная
ДАРУЛЫ РОМАШКА — ромашка аптечная
ДАРУЛЫ СУКЫР КЫЧЫТКАН — пустырник сердечный
ДАРУЛЫ СӨЛӘЙМАН МӨҺЕРЕ *(дарулы төйләмә)* — купена лекарственная
ДАРУЛЫ ТУЗГАНАК — одуванчик лекарственный



ДАРУЛЫ ТӘКӘМӨГЕЗ — донник лекарственный
ДАРУЛЫ ЧАЛГЫЧУТ — гулявник лекарственный
ДАРУЛЫ ЧЫПЧЫК ҮЛӘНЕ — воробейник лекарственный
ДАРУЛЫ ШАЛФЕЙ — буквица лекарственная
ДАРУЛЫ ЯУШАН — вероника лекарственная
ДАРУЛЫ ӘСПЕ ҮЛӘНЕ *(чебен үләне)* — спаржа лекарственная
ДАРЧИН АГАЧЫ — корица, коричное дерево
ДЕКОРАТИВ АСЫЛМАЛЫ ҮСЕМЛЕКЛӘР — растения ампельные
ДЕКОРАТИВ ҮСЕМЛЕКЛӘР — растения декоративные
ДЖУТ *(һинд сүсе)* — джут
ДИҢГЕЗ БҮЛБЕ-КАМЫШЫ — клубнекамыш морской
ДИҢГЕЗ КӘБЕСТӘСЕ *(суүсем)* — морская капуста
ДИҢГЕЗ НАЯДАСЫ *(зур наяда)* — наяда морская
ДИҢГЕЗ САЛАТЫ *(суүсем)* — ульва, морской салат
ДРИАДА *(көртлек үләне)* — дриада, куропаточная трава
ДУҢГЫЗ АЙРАВЫГЫ — ежа сборная
ДӘЛИЯ — георгин
ДӘФНӘ АГАЧЫ *(лавр)* — лавр
ДӨГЕ — рис
ДӨГЕ ҮЛӘНЕ — леерсия рисовидная
ДӨЯ БОРЫЧЫ — очиток
ДӨЯ ЧӘНЕЧКЕСЕ *(үлән)* — верблюжья колючка
ДӨЯ ҮЛӘНЕ — верблюжья трава
ДҮЛӘНӘ — боярышник
ДҮҢГӘЛӘК *(давыл үләне)* — качим метельчатый, перекати-поле
ДҮҢКӘЛ *(ирга)* — ирга

## Е

ЕВРОПА АРЫСЛАН ТЫРНАГЫ — зюзник европейский
ЕВРОПА КАЗАЯГЫ *(алтынтүй чәчәге)* — купальница европейская
ЕВРОПА ТАЙТОЯГЫ — копытень европейский
ЕВРОПА ТАЛАКДАРЫ *(европа җидегән уты)* — седмичник европейский
ЕВРОПА ЧОРМАВЫГЫ — повилика европейская
ЕЛАН АБАГАСЫ *(елан теле)* — ужовник обыкновенный
ЕЛАН ТАМЫРЫ *(кысла муены)* — горец змеиный
ЕЛГА БУЕ КЫНДЫРАГЫ *(солы үләне)* — костер береговой

ЕЛГА КЫСЫР ТИГӘНӘГЕ — гравилат речной
ЕФӘК АГАЧЫ *(тут агачы)* — шелковица, тутовое дерево
ЕШКУЛ *(дала ешкулы)* — ясколка дернистая

## Ж

ЖЕНЬШЕНЬ *(тереклек тамыры)* — женьшень

## З

ЗЕЛПЕ — жимолость
ЗИБЫК УТЫ *(бал чәчәге)* — пролесник
ЗИРЕК — ольха
ЗИФА КЕЛЕРИЯ *(кыяклы үлән)* — келерия стройная, тонконог
ЗООСПОРАНГИЙ *(орлыклар ясалу-үсү урыны)* — зооспорангий
ЗУР ӘРЕКМӘН — лопух большой
ЗӘЙТҮН *(агачы һәм җимеше)* — маслина
ЗӘНҖӘБИЛ *(тропик үсемлек)* — имбирь
ЗӘРДӘ *(бизгәк үләне)* — василистник
ЗӘҢГӘРСУ ПЕСИ ТАРЫСЫ — щирица синеватая
ЗӘҢГӘР УМЫРЗАЯ — печёночница благородная, синий подснежник
ЗӘҺӘР ВАКБАШ — мелколепестник едкий
ЗӘҺӘР КАЗАЯК — лютик едкий
ЗӘҺӘР КЫЧЫТКАН *(тимер кычыткан)* — крапива жгучая
ЗӘҺӘР КӘРЛӘЧ *(ачы дөя борчагы)* — очиток едкий

## И

ИГҮЛЕ КИНДЕР *(киндераш)* — конопля посевная
ИГҮЛЕ ЛЮЦЕРНА — люцерна посевная
ИГҮЛЕ ҮСЕМЛЕКЛӘР — агрофиты
ИГҮЛЕК САЛАТ — салат огородный, латук посевной
ИКЕЕЛЛЫК КАЧЫР ҮЛӘНЕ *(икееллык ишәк үләне)* — ослинник двулетний
ИКЕЕЛЛЫК ҮСЕМЛЕКЛӘР — двулетние растения
ИКЕ КАНАТЧА *(мәс., өрәңгедә)* — двукрылатка
ИКЕ КАТЛЫ ЧӘЧӘК ТИРӘЛЕГЕ — околоцветник двойной
ИКЕ РӘТЛЕ АРПА — ячмень двурядный
ИКЕ ӨЙЛЕ КЫЧЫТКАН — крапива двудомная



ИКЕ ӨЙЛЕ ҮСЕМЛЕКЛӘР — растения двудомные
ИКЕ ӨЙЛЕ КҮРӘН — осока двудомная
ИКЕ ӨЙЛЕ ПЕСИ ТӘПИЕ *(ике җенесле песи табаны)* — кошачья лапка двудомная
ИКЕ ӨЛЕШЛЕ ҮСЕМЛЕКЛӘР — растения двусемядольные
ИКЕ ҖЕНЕСЛЕ ЧӘЧӘК — цветок обоеполый
